


# ”Баш иябез Бөек елларга”

# 1941-1945

## Бөек Ватан сугышы чоры балалары турында Хәтер альбомы

## Юлбат, Тенеки, Йосыф - Алан, Калатау авыллары буенча

Сугыш... Меңләгән шәһәрләр җимерелгән, җир йөзеннән гөрләп торган авыллар юкка чыккан, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып көлгә әйләнгән. Әйе... Барлык ир-егетләр сугышка китәләр, авылда картлар, хатын-кызлар, балалар кала. Ә тормышны алып барырга кирәк - игенен дә игәргә, балаларны да ач-ялангач итмәскә, сугыш кырына икмәген, коралын да озатырга, бик зур салымын да түләргә кирәк була.

Әйе, сугыш сабыйларга да ир-егетләр җаваплыгы салган. Балачакның бала казлары вак-вак адымлы шул алар. Шуңа күрә озын - озактыр ул балачаклар… Табышмаклар әйтешеп, казлар санап, яшәргә өйрәнгән ул көннәрдәндә, сугыш гарасатытынганнан да байтак еллар үтсә дә, аларның югалту ачылары бик ачы, яралары һаман ачык, күз яшьләре бик кайнар әле… Без тарих итеп тыңлаган хикәятләрдә аларның үз башларыннан үткән хатирә бит.

Сынаган аларны бу дөнья! Утларына салып яндырса да, бозларына салып туңдырса да, сындырмаган, шөкер бу дөнья! Ә бит сындырырдай итеп сынаган…

Һәр өченче малай һәм кыз баланың әтисе, Ватанны фашизм коллыгыннан саклап, яу кырында ятып калган. Сугыштан соң аталы балалар ата-ананың тигез канаты астында җылыга коенганда, алар сыңар канат астында «әти» дип әйтергә тилмергән. Япь - яшь килеш канатлары каерылган чибәр хатыннар солдат ирләренә булган мәхәббәтне гаҗәеп тугрылыкны соңгы сулышларынача саклаганнар. Аларны сагынып яшәгәннәр. Шул хисләрне балаларына да күчергәннәр. Шуңа күрә сугыш чоры энилəре һәм сугыш чоры балалары – шул алар.


Сугыш һәркем өчен төзәлмәс яра. Балалары өчен бер авыр булса, аналары өчен 5 авыр булган. Шулай шул, матур затларның, бала-чаганың куллары ул елларда тупасланды, атларны алыштырып җир тырмашып сабан - сука тарттылар. Бар авырлыкка да тешләрен кысып түзделәр. Дөнья хәтерли. Илем өстенә фашист явы ябырылганда хатын-кызлар, балалар да фронтта һәм тылда җиңү көнен якынайту өчен көрәштеләр.

Сугыш беткәнгә дә 72 ел җитеп килә, әмма аның дәһшәте – көл булган шәһәр авыллар өстендә, яу кырыннан кайтмый калган ир-егетләр, әти-бабалар каберлегендә. Аның сары сагышы әтисезләр йөзендә. Алар сугыш дигән ачы хәсрәтнең фаҗигасен туганнан ук тоеп, үз күзләре белән күреп, ачлык-ялангачлыкның ни икәнен татып үскән. Алар утлы елларда туган балалар. Шуңа күрә сабыр, нык алар.

Әйе, сугышның утлы мәхшәре безнең Юлбат халкын да читләтеп үтмәгән. **Коточкыч сугышта Юлбат авыл җирлегеннән 289 якташыбыз катнашкан.**

| Авыл исеме | Катнашканнар | Исән- сау әйләнеп кайтканнар | Вафат булганнар |
|---|---|---|---|
| Юлбат | 120 | 40 | 80 |
| Тенеки | 112 | 32 | 78 |
| Йосыф - Алан | 37 | 12 | 25 |
| Калатау | 20 | 11 | 9 |

Без сезне шул чорларның бар авырлыгын үз җилкәсендә татыган, үсмер еллары сугыш чорына туры килгән, олы ихтирамга лаек кешеләр, бүгенге көндә балаларының таянычы, оныкларының юанычы булып яшәүче авылдашларыбыз сугыш чоры балалары турындагы истәлекләребезне барлыйбыз.



# Ахтямов Гәптелмәннәф Гәпсәләм улы

Туганелы: 1 апрель 1943 ел

Туган урыны:ТАССР Кукмара районы Чишмәбаш авылы.

Әтисе Гәпсәләм 1941 елда сугышка китә. **1942 елда яраланып кайта.** Гаиләдә сигез бала үсәләр. Сугыштан соңгы еллар алар өчен бик авыр булган. Кечкенә булуга карамастан авыр эшләрдә катнашырга туры килгән.

Кукмара районы Зур Сәрдек мәктәбендә 11 класс укый. Аннары Казан шәһәрендә 2 ел төзелештә эшли. 1964 елны Казан Авыл хуҗалыгы институтының агрономнар әзерләү факультетына укырга керә. Аны 1969 елда тәмамлый һәм Саба районы “Авангард” колхозына баш агроном итеп билгеләнә. Анда 3 ел эшли. 1972 елда Саба районы КПСС райкомында оештыру бүлегенең инструкторы була. Ә 1973 елның 15 январеннән Саба районы “Искра” колхозына колхоз рәисе итеп сайлана. Ул рәис булган елларда бөртекле ашлык һәм бәрәңге үстерү буенча “Искра” колхозы районда беренчеләрдән була. Бу елларда колхозчыларның социаль тормышы уңай якка үзгәрә. Авылда елга аша зур күпер салына, яңа мастерской, зур мәдәният йорты, бәрәңге саклау подвалы, нефтебаза, фермалар төзелә. Авылда сигезьеллык мәктәп ачыла. Амбарда ашлык киптерү өчен Польшада эшләнгән КЗС агрегаты төзелә.

**Гәптелмәннәф Гәпсәләм улына 1976 елда “Ударник девятой пятилетки”, ә 1975 елда “Победитель социалистического соревнования 1974 года” знаклары бирелә. Татарстан АССР Верховный Советы президиумның 1980 елның 13 июнь Указы белән Хуҗалык һәм культура төзелешендә актив катнашканы өчен һәм Татарстан АССРның 60 еллыгы уңае белән Татарстан АССР Верховный Советы президиумы Почет Грамотасы белән, 2003 елның апрель аенда Татарстан Республикасы Саба районы хакимияте Авыл хуҗалыгы өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Мактау Грамотасы белән бүләкләнә. Ә 2001 елның 12 мартында игенчелектәге уңышлары өчен Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Авыл хуҗалыгы производствосы өлкәсендәге казанышлары өчен “Татарстан Республикасының Атказанган агрономы” дигән мактаулы исем бирелә.**



# Ахтямова (Харрасова) Фәрәһия Гыйләҗетдин кызы

Туган елы: 2 январь 1934 ел.

Туган урыны: БАССР Илеш районы Рсай авылы.

**Әтисе Гыйләҗетдин труд армиядә булган. Аннан 1947 елда кайта** һәм озак та тормыйча шул елны ук үлә. Гаиләдә 8 бала әнисе Мәфтүхулҗинан тәрбиясендә кала. Олы абыйсы

Мирһади 1941 елдан 1945 елга хәтле сугышта катнаша. Ул Ленинград чолганышында була. Сугыштан 1946 елда гына кайта. Авырып, ачлыктан бер-бер артлы 4 абыйсы һәм сеңлесе үлә. Фәрәһиягә сугыш башланганда 7 яшь була. Сугыш елларының ачлыгын да, авырлыгын да кичергән. Башак һәм бәрәңге җыюда катнашкан.

БАССР Илеш райны Рсай сигезьеллык һәм Дөмәй урта мәктәбендә ун класс белем алган. Аннан соң Чиләбе шәһәрендә тимер юлда 1 ел, трактор заводында 1966 елга кадәр эшләгән. Заводның үзешчән театрында уйнаган. 1967 елда тормышка чыгып Казан шәһәренә килгән. Анда кинотеатрда эшләгән. Аннары Саба районы Юлбат медпунктында эшләп пенсиягә чыккан.

Бүгенге көндә алар Татарстан Республикасы Саба районы Юлбат авылында Гәптелмәннәф абый белән гомер итәләр. Өч кыз тәрбияләп үстерделәр.





## Әһлиева (Кәримова) Дания Кәрим кызы

1939 елның 28 апрелендә Тенеки авылында туган.

Гаиләдә 5 бала үскәннәр.

“Сугыш башлангач, тормыш бик авыр булды. Ашарга табулары авыр иде. Ашарга яраклы яшеллек белән тукландык. Үскәчтә рәхәт вакыт булмады. Басуда кыр эшләрендә булыштык: җитен, борчак йолыктык, башак җыештык. Ачлыгын да күрдек, өстебезгә кием дә булмады. Шунысы сөенеч булды сугыш афәтен үз күзләребез белән күрмәдек, бомбалар шартлаганын ишетмәдек”, - ди ул.

7 нче сыйныфны бетерүгә фермада эшли башлый.

**1980-1982 елларда “Лучшая овцевод колхоза” ордены, “За доблестный труд в ознаменование 100 - летия со дня рождения Владимира Ильича Ленина”, III дәрәҗә “Хезмәт даны” ордены, “Хезмәт ветераны” медале белән бүләкләнә.**

Хәзерге вакытта улы Ильдус һәм килене Ризәлә тәрбиясендә Тенеки авылында яши.

## Әмирова (Котдусова) Рәйхана Котдус кызы

1942 елның 14 январендә Тенеки авылында туган. Гаиләдә 4 кыз бала дөньяга килгән. **Әтисе сугышта катнашып, 1942 елда һәлак булган.** Тенеки клубында җыештыручы булып эшләгән. Тенеки авылы егете Рәҗәп абый кияүгә чыгып 3 бала тәрбияләп үстергәннәр. Хәзерге көндә улы Дамр гаиләсендә Тенеки авылында гомер кичерә.



# Әһелова (Ихсанова) Сәвия Ихсан кызы

Сугыш... Нинди шомлы һәм авыр сүз бу! Улничә миллион кешенең гомерен өзгән, күпме баланы ятим иткән, аналарны тол калдырган.

Сугыш... Меңәрләгән шәһәрләрне җимергән, җир йөзендә гөрләп торган авылларны юкка чыгарган, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып, көлгәәйләнгән.


“Әй, язмыш, язмыш... Узган юллар, узган еллар, мизгелләр кинодагы кебек күз алдыннан үтә. Миңа да гомер юлымданиләр генә күрергә туры килмәде.

Сугыш елларын ишетеп белгәнгә, алар кабат-кабат хәтерне яңарта, йөрәкне әрнетә. Мин 1936 нчы елның 5 нче мартында Саба районы Юлбат авылында дөньяга килгәнмен. Сугыш башланганда мин әле кечкенә, нибары биш яшьтә генә идем. Әтием Исламов Ихсан 1899 нчы елда туган. **Сугышта катнашкан кеше.** Әнием Сания4 бала белән калган. “ – дип, сөйләп китте әбием Сәвия, сугыш турында хәтирәләрен барлавын үтенгәч.

Алар әтиләрен күпме күз яшьләре түгеп сугышка озатканнар. Әбиемнең әнисе ашларны да үләннәрдән пешергән, алар алабута ипиләре ашаганнар, басулардан черек бәрәңгеләр җыеп, аннан кәлҗемә ясап пешереп ашаганнар. Ул вакытта аякларга аяк киеме дә булмаган, өскә кияргә дә ике-өч кешегә бер кием булган. Урлаулар да булмаган, әгәр дә кесәндә бер уч бодай тапсалар, ул кешене биш елга төрмәгә утырткannar. Сугыш булуга карамастан алар барыбер бәйрәмнәр уздырганнар. Сабан туйлары ясаганнар, ташу башланган вакытта бөтен авыл тау астына төшеп ташу акканын караган. Алар бик күп эшләгәннәр. Әти киткәннән соң бөтен эш әнием өстендә кала. Тормышны алып барырга кирәк бит. Урак тотып басуга чыгу, кара җиргә иелеп, андагы төшеп калган бодайларны җыеп эссе кояш астында йөрү дисеңме. Борчак вакытында борчак йолкышулар,- дип еламсырап искә ала әбием әнисен. Алар гел сугыш бетәр әти кайтыр дигән өмет белән ышанып яшәгәннәр. Һәм әлбәттә бу ышаныч акланган. **Әбиемнең әтисе сугыштан исән-сау кайта.** Тормышындагы иң истә калган вакыйгасы мөгаен шул булгандыр әбиемнең.

Әбиемнен бер генә теләге бар: бүтән мондый сугышлар, ачлык, ялангачлык вакытлары кабатланмасын. Амин. И, Ходаем! Без нindirәхәт, матур, тынычтормыштаяшибезикән. Буяшьлекнеңкадерен, тормышныңяменбелепяшик,- дип тәмамлады әбием хәтирәләрен.

Әлеге язма оныгы Диләрә тарафыннан Сәвия әби истәлекләреннән барланды.




# Фатыйхова (Мөбәрәкшина) Дания Дәүли кызы

1940 елның 1 январендә Юлбат авылында дөньяга килә. Юлбат башлангыч, Сатыш җидееллыгын тәмамлый. Әтисе 1941 нче елның октябренә кадәр сугышта. 1941 нче елның октябреннән 1945 нче елның маена кадәр Германиянең Ленаб шәһәре янында хәрби әсирләр лагеренда әсирлектә була.
Гаиләдә 6 бала үсә: 1 кыз, 5 малай. Ләкин сугышка кадәр үзе генә, калган балалар сугыш беткәч дөньяга киләләр. Үзем сугыш башланганда 1,4 айлык кына булганлыктан, әни сөйләгәннәрдән генә әйтәм. Сугыш елларында ашарга, ягарга утын булмаган, салам ягып яшәгәннәр. Ул вакытта бик күп авырлыклар кичергәнбез. Ашарга кычыткан, алабута, чыпчык кузгалагы, черек бәрәңге ашап туенганбыз. Бик яшьли эшли башладым. Юлбатта сарык фермасында, бозау карауда эшләдем.- дип хәтирәләрен яңартты



ул. **Тырыш хезмәте өчен “Ударник девятой пятилетки” знагы белән бүләкләнә һәм “Ударник коммунистического труда” значогы бирелә.** Лаеклы ялга Юлбат мәдәният йортында җыештыручы булып эшләп чыга. Вазыйх абый белән 51 ел бер-берсенә терәк, балаларына үрнәк булып, иңне - иңгә куеп Юлбат авылында яшиләр.



# Фатыйхов Вазыйх
# Фатыйх улы

1940 елның 15 февралендә Юлбат авылында 4 бала булып дөньяга килгән. 7 класс белем ала. Әтисе **Гарипов Фатыйх 1941 елда сугышта хәбәрсез югала.**

Гаиләдә 4 бала: 3 малай, 1 кыз туа. Өч бертуганы бала вакытта ук үлгән. Сугыш башланганда,аңа ни бары 1,4 ай була. Шул сәбәпле, әтисен бөтенләй хәтерләми. Үсмер чактагы авырлыклар хәтерендә бик нык уелып кала. 10,11,12 яшьтә җәй көне ат, 13 яшьтә олылар белән төнге көтү көтә. 14 яшьтә 7 класс бетергәч колхозда эшли башлый. Ат җигеп кыш көне малларга салам, су җылыту өчен урманнан утын ташыганнар. Ат җигәргә буем җитмәгәч күрше Ибраһим абый җигеп бирә иде,- дип искә ала ул. 18-19 яшьтә басудагы тракторларга 200 кг лы бочка белән су һәм ягулык ташый. 1959 елның августында Армия сафларына кабул ителә. 1961 елның июль аенда изге бурычын үтәп кайта. 1961 елның көзендә Мамадышта 4 айлык шоферлар курсында укып, шофер булып эшли башлый. 1967- 68 елларда Алабугада электриклыкка укый. Аннан кайткач төрле эшләрдә эшли. 1973 елдан 2012 елга кадәр “Искра” колхозында электрик булып эшләп лаеклы ялга чыга.


1965 елның март аенда өйләнеп тормыш иптәше Дания апа белән 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта Юлбат авылында яшиләр.





## Ганиева (Зәкиева)
## Мәрьям Зәки кызы

1939 елның 1 сентябрендә Саба районы Мәртен авылында туган. 4 класс белеме бар. 13 яшьтә Мәртендә сарык фермасында эш юлын башлап җибәрә. Сарык фермасы бетерелгәч 10 ел сыер сава. 1965 елның 7 ноябрендә Юлбат авылы егете Ганиев Абуталип Гани улына кияүгә чыга. Сугыш вакытында әниләре Газиләгә 4 бала калалар. **Әтиләре сугыштан кайтмаган.**



## Ганиев Абуталип Гани улы

1939 елның 27 мартында Юлбат авылында туган. Башлангыч мәктәпне Юлбат 4 еллык мәктәбендә укый. Сатыш мәктәбенә йөреп 7 сыйныфны тәмамлый. 1955 елдан колхозда прицепщик булып эшли башлый. 1958 елны тракторчы - машинист һөнәрен ала. 1960 елда тракторист булып эшли башлый. 2000 елга кадәр шушы һөнәренә тугры калып Юлбат колхозында хезмәт куя. Эшләү дәверендә бик күп орден - медальләргә лаек була. **1970 елда “За доблестный труд” медале, Вознаименование 100 летия со дня рождения В.И.Ленина медале тапшырыла. 9,10,11,12 нче бишьеллык знакларына лаек була. 1975 елда “Знак почета ордены белән бүләкләнә. 1977 елда “Авылның иң яхшы механизаторы” дигән исем ала. 1985 елда “Атказанган механизатор” исеме бирелә. Аның бик күп почет грамоталары бар**. Хатыны Мәрьям белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр. 7 оныклары бар. 2016 елда “Алтын туй” ларын билгеләп үттеләр. Хәзерге вакытта уллары Альберт һәм киленнәре Мәүлия белән Юлбат авылында яшиләр.Әтиләре сугышка киткәндә әниләре Мәймүнә 2 бала белән кала. Әтисе 1941 елда сугышка алына. **1942 елның сентябрендә үлгән хәбәре килә.**







# Билалов Данил Билал улы



1939 елның 5 октябрендә Юлбат авылында туган. 1947 елда Юлбат 4 еллык мәктәбенә укырга керә. Күрше генә Сатыш авылына йөреп 7 классны тәмамлый. Яшь чагында колхозның төрле эшләрендә ат җигеп эшли. Язын сука сукалый, көз көне амбарга ящиклы арбалар белән икмәк ташый. Армиягә киткәнче ДТ тракторындагы сукада плугар булып эшли. 1961 елда Армия сафларына алына. Мәскәүдә хезмәт итә. Кайткач Саба район училищесында шоферлыкка укый һәм һөнәре буенча лаеклы ялга чыкканчы эшли. Мактау грамоталары белән бүләкләнә. Сугыш вакытында әниләре Гөлсем 4 бала белән кала. **Әтиләре Билал сугыштан исән сау кайта.** Яңадан 5 балалары дөньяга килә. Хәзерге вакытта Юлбат авылында яши.



# Галимуллин Рәфкәт Галимулла улы

1939 елның 12 июнендә Юлбат авылында туганмын. Сугыш вакытында, аннан соң да тамак ипигә туймаганын оныта алмыйм.

Сугыш вакытында семьяда 5 бала: 3 апа, мин һәм сеңлем. **Әти гражданнар сугышы ветераны. Яше чыгу сәбәпле, Бөек Ватан сугышында катнашмаган.** Яшем җиткәч колхозда төрле эштә эшләдем. Утыз ел тракторда эшләп, 41 ел стаж белән лаеклы ялга чыктым. Тормыш иптәшем Юлбат авылы кызы Бәрия белән бер кыз тәрбияләп үстердек. 2 оныгым һәм бер оныкчыгым бар. Бүгенге көндә пар канат булып Юлбат авылында яшибез,- дип тәмамланды сүзен.



# Нуретдинова (Кадыйрова) Галия Кадыйр кызы

1937 елның 12 декабрендә Юлбат авылында туганмын. Миңа сугыш башланганда 3-4 яшь иде. Сугыш елларында 3 бала идек. Минем әтием сугышка бармады. Аның сул кулының бармаклары өзелгән иде. Гомер буе фермада эшләдем. Пенсиягә дә шуннан чыктым. Мин Калатау егете Нуретдинов Гилметдин белән тормыш корып, 3 бала тәрбияләп үстердек. Хәзерге вакытта Йосыф - Алан авылында олы улым Гомәр киленем Нурфия һәм ике оныгым белән яшим.

# Кәлимуллина(Гаптрахманова) Хәния Гаптрахман кызы





1944 елның 8 маенда Шытсу авылында туа. 7 класс белеме бар. Сугыш вакытында 5 бала булалар. **Әтисе сугышта катнаша, бер аягын өздереп кайта.** 7 классны тәмамлауга фермада сыер савучы булып эшли башлый. Эшләгән дәвердә исеме Почет тактасыннан төшмәгән. Кәлимуллин Рәшиткә кияүгә чыгып 5 бала тәрбияләп үстергәннәр. Балалары барысы да тормышлы. Хәзерге вакытта Калатау авылында улы Ильнур гаиләсе белән яши.



# Хуҗина (Фәрхетдинова) Тәгъзимә Фәрхетдин кызы

1940 елның 24 февралендә Юлбат авылында туган. Белеме 5 класс. Яшьтән эшли башлый. 3 ел торфтада эшләп кайта. Колхозда яшь бозаулар караучы булып, комбайнер ярдәмчесе дә булып эшләргә туры килә. Озак еллар колхозда тырыш хезмәт куйган өчен почет граматосы, орден һәм медальләре белән бүләкләнә. **1981 елда “Иң яхшы бозау караучы” грамотасы белән бүләкләнә.**



1963 елда Юлбат авылы егете Хуҗин Авангард белән тормыш корып җибәрәләр. Алар 5 бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта төпчек уллары Марсель һәм килене Алсу белән яши.

Сугыш чорында алар 2 бала булганнар. 1941 елның августында әтисе **Фәрхетдин бабай сугышка китә. 1945 елның сентябрендә исән - сау әйләнеп кайта.**




# Фәсхетдинов Рәфис Фәйзрахман улы

1942 елның 1 маенда Калатау авылында туа. Гаиләдә 6 бала үскәннәр. **Әтисе сугышта катнашкан, исән-сау 1945 елда көз көне кайткан**. Балачак истәлекләреннән сөйләгәннәрдән: “Алабута орлыгы җыярга бардык, бик каты болыт килде, яңгыр ява башлады. Курыктык. Абыйлар белән арба астына кереп качтык”,- дип искә төшерде.

1961 елда Совет Армиясе сафларына бара. 3 ел хезмәт итә. Армиядән кайткач колхозда эшли. 1970 елда Юлбат авылы кыз Асия апа белән тормыш корып җибәрәләр. 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта Калатау авылында яши.







# Абдуллина (Җәләлиева)
# Кәүсәрия Зәкәрия кызы

1937 елның 16 январендә Тенеки авылында туган. 7 класс бетергән. Сугыштан соң бик авыр булды. Ашарга ризык юк. Кычыткан, черек бәрәңге ашадык. Басуга башак җыярга, чүп утарга йөрдек. Шунысы куанычлы өстебезгә бомба төшеп, пуля яумады, - ди. Ипилек булса да акча булмасмы дип, 6 класстан соң кирпич заводында тачка белән кирпич йөрткәннәр. Гаиләдә 3 бала үскәннәр. Әтисе сугышта катнашкан. **1944 енең февралендә хәбәрсез югалган**. Йосыф-Алан егете Әхәт абыйга кияүгә чыгып, 5 бала үстергәннәр. **Бүләкләре: “Коммунистик хезмәт ударнигы”, “Социалистик ярышлар җиңүчесе”, Хезмәт ветераны**. Йосыф - Алан авылында яши.



# Хәсәнов Мөхәммәтнур Зәки улы

1944 нче елның 20 нче июлендә Саба районы Тенеки авылында туа. Гаиләдә 5 бала булганнар. 9 класс укыган. Аннары Тукай авыл хуҗалыгы техникумына укырга кергән һәм зоотехник белгечлеге алган. Хезмәт юлын Управлениедә башлаган. 1972 нче елда Икшермә авылында зоотехник булып эшләгән. 1973 нче елда Саба май заводына эшкә урнашкан. Анда лаеклы ялга чыкканчы эшләгән. Тырыш хезмәте медальләр һәм мактау кәгазьләре белән бәяләнгән.



# Хәсәнова (Хөснетдинова) Фәния Карам кызы

1945 нче елның 1 августында Теләче районы Иске Җөри авылында туган. 7 класс белеме бар. Бик яшьләй авыр хезмәт башкарырга туры килгән. Грузчик булып та, төрле эшләр башкарырга да, сыер да саварга туры килгән аңа.Тырыш хезмәте өчен районның “Почет китабы” на кертелгән. **Әтисе сугышта булган, кайткач,** Казан шәһәрендә военный заводта эшләгән. Гаиләсен дә Казанга алып китәргә теләгән. Ләкин әниләре китәргә каршы булган, авылда яшәүне кулайрак күргән. Шулай итеп гаилә авылда гомер кичергән.5 балалы гаилә 3 баласын соңгы юлга озаткан. 4 класста укыган абыйсы минингит авыруыннан, аның 51 е көнне эче авыртып икенче абыйсы һәм 19 яшендә бик тиз генә авырып апасы да үлеп киткән.

Хәсәнов Мөхәммәтнур Зәки улы беләнХәсәнова (Хөснетдинова) Фәния Карам кызы 1972 нче елда гаилә корып яши башлаганнар. Өч бала тәрбияләп үстергәннәр. Балалары бүгенге көндә үз тормышлары белән яшиләр. Мөхәммәтнур абый белән Фәния апа аякка, өскә кияргә дә, туйганчы ипи дә ашарга мөмкин булмаган ул заманнарның авырлыгын әйтеп-аңлатып бирергә сүзләр дә таба алмыйбыз диләр. Ә бүгенге көнгә бик шөкер итеп яшиләр.



# Дәүләтова (Галимбикова) Хаҗәр Әхбәр кызы

Туган урыны: Теләче районы, Иске Җөри авылы
Туган көне: 30.07.1941
Белеме: 7 класс
Гаилә составы: 2 кеше
Соңгы эш урыны һәм эш вазифасы: техник хезмәткәр, Юлбат мәктәбе.
Социаль статус:лаеклы ялда.

**Әтисе Әхбәр Бөек Ватан сугышында катнаша, исән –сау кайта.** Гаиләдә 3 бала: 3 кыз туа. Сугыш еллары бик авыр булып истә калган. Миңа имезлек салырга да әйбер булмаган,- дип искә ала Хаҗәр апа. Әнисе алабута, кычыткан, күмәчләр пешереп ашата, ачлыктан шулай алып кала. Ягарга апалары чыбык – чабык алып кайта. Апалары әниләренә ияреп колхозга эшкә дә чыга.

Хәзерге көндә Юлбат авылында тормыш иптәше Вафи белән яшиләр. Балалары юк.




# Фәесханов Вафи Фәесхан улы

Туган урыны: Саба районы, Юлбат авылы
Туган көне: 01.08.1935
Белеме: 7 класс
Гаилә составы: 2 кеше
Соңгы эш урыны һәм эш вазифасы: “ Искра” колхозында төрле эш башкара.
Социаль статус:лаеклы ялда.

**Әтисе Фәесхан Бөек Ватан сугышында һәләк була.** Гаиләдә 4 бала: 1 малай, 3 кыз туа. Сугыш елларында әни безне ач-ялангач итмәс өчен бик тырышты,- дип искә ала Вафи абый. Сугыштан соңгы елларда колхозда эшли, армия сафларына алына.

Өйләнгән, бүгенге көндә тормыш иптәше Хаҗәр апа белән Юлбат авылында яшиләр.



# Рәхмәтуллин Сәетвәли Ибәтулла улы

Туган урыны: Чиләбе өлкәсе, Карабаш шәһәре
Туган көне: 16.06.1937
Белеме: 7 класс
Гаилә составы: 2 кеше
Гомуми эш стажы, соңгы эш урыны һәм эш вазифасы : 36 ел, “ Искра” колхозында механизатор.
Социаль статус: лаеклы ялда.

Гаиләдә 4 бала: 2 малай, 2 кыз туа. Әтисе Ибәтулла Бөек Ватан сугышында катнаша, **1941 елда хәбәрсез югалган.** Әнисе ашханәдә эшләгән, тамак ач булмады. - дип искә ала. Үсмер чакта бар эшне дә рәттән эшләдек ди. 1957 елда армия сафларына алынып, 3 ел хезмәт итә. 1961-1997 елларда “Искра “ колхозында КСК 100 комбайнында эшли. Һәр елны Мактау кәгазьләре белән бүләкләнә.

1960 елда өйләнеп тормыш иптәше Нурия белән 1 бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта Юлбат авылында тормыш иптәше Нурия белән улы Илфир тәрбиясендә яшиләр.



# Мәүлина (Вәлиева) Бибирәвкия Вәли кызы

Туган урыны:  Саба районы, Юлбат авылы
Туган көне: 26.01.1941
Белеме: 10 класс, 1988 елда кичке мәктәпне тәмамлый.
Гаилә составы: 1 кеше
Гомуми  эш стажы, соңгы эш урыны һәм эш вазифасы : 37 ел,  Юлбат авылы, почтальон.
Социаль статус:лаеклы ялда.
Дәүләт бүләкләре, исеме:  **22.06.1998 ел., “Ветеран труда” медале.**
Гаиләдә 3 бала: 1 малай, 2 кыз туа.  Әтисе Гәрәев Вәли  Бөек Ватан сугышында катнаша,  **1943 - 1945 еллар тирәсендә һәлак була. Новгород өлкәсе Вещана авылында җирләнүе билгеле**. Бәрәңге җиреннән яз көне черек бәрәңге җыеп, кабартма, сөт булса, әзрәк сөт салып, кычыткан ашы пешерү, Алан түбәсендә урак уручы әниләр янына, кайнаган суга болгаткан онлы апараны ашау өчен  ялан аяк  бару әле дә истә,-  дип искә ала Бибирәвкия апа. Гаиләгә көчебездән килгәнчә файда китерергә тырыша идек : әниләргә 3 әр капчык борчак өләшәләр. Шул борчак арасыннан симәнәгә ярардай әйбәтләрен генә сайлыйбыз. Гаиләгә зур ярдәм була иде, шушы эшләренә карап әниләргә хезмәт хакы түләнә иде.

Тормыш иптәше Хәким абый белән 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Күп тапкырлар авыл советы депутаты итеп сайлана, авылның җәмәгать эшләрендә актив катнаша, Мактау грамоталары белән бүләкләнә. 1995 елдан лаеклы ялда.

Бүгенге көндә ире, 2 баласы мәрхүм. Хәзерге вакытта Юлбат авылында кызы Гөлсинә тәрбиясендә яши.



# Җәләлиева (Идрисова) Нәкыя Зиннәтулла кызы

1939 елның 13 августында Кукмара районы Мәмәшер авылында туган. Сугыш афәтен, өскә бомбалар төшкәнен күрмәдек, шунысы сөенеч булды. Ул елларда ачлык, кияргә кием булмады. Тишек чабата киеп бәләкәй арба белән утын ташыдык.

Сугыш вакытында гаиләдә үзем генә идем, **Әти сугышта катнашып исән - сау әйләнеп кайтты.** Сугыштан соң әти кайткач 3 сеңлем дөньяга килде.

Гомер буе фермада эшләдем. Тавык, сарык аннары сыер фермасында хезмәт куйдым. **1986 елда “Почет билгесе” ордены белән бүләкләндем.** Хезмәт ветераны. Хәзергесе көндә тормышымнан кәнагать, аллага шөкер,- дип сүзен тәмамлады. Тенеки егете Габделфәрит абый белән тормыш коралар. 5 бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта пар канат булып Тенеки авылында яшиләр.



# Җәләлиев Габделфәрит Зәкәрия улы

1939 елның 1 январендә Тенеки авылында туа. Гаиләдә 4 бала үсәләр. Бик бәләкәйдән эшли башладык. Амбарда, фермада эшләдем. 4 ел Совет армиясе сафларында хезмәт иттем. Мәктәптә укыган вакытлар бик истә. Юл юк иде. Кыш көне мәктәпкә боз өстеннән йөрдек, - дип хәтирәләрен яңартты ул. Тормыш иптәше Нәкыя апа белән Казахстанда танышып, шуннан кайтканнар. 1960 елда өйләнешеп 5 бала тәрбияләп үстергәннәр. Бүгенгесе көндә кече уллары Ильнур тәрбиясендә яшиләр.



# Сәләхова (Ибәтова) Шәфига Ибәтулла кызы



1941 елның 15 февралендә Юлбат авылында туган. Сугыш вакытында без алдагы көнгә өмет белән яшәдек. Безнең әниебез бик тырыш иде, аның ярдәме белән без исән калганбыз. Сугыш башлангач, тормыш бик авыр булган. Ашарга яраклы барлык яшеллек белән тукланганбыз.. **Әтисе сугышта катнашкан. Исән-сау әйләнеп кайткан**. Гаиләдә 6 бала. 4 се сугышка кадәр, 2 се сугыштан соң туганнар. Белеме 7 класс. 7 классны тәмамлауга 6 ел сарык фермасында эшли. 1964 елда Юлбат егете Сәләхов Әхтәри абыйга кияүгә чыгып 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Колхозда төрле эшләрдә эшли. Соңгы алты елын пенсиягә чыкканчы Юлбат мәктәбендә җыештыручы булып лаеклы ялга чыга. Бүгенге көндә тормыш иптәше белән Юлбат авылында яшиләр.



Хәзерге буын**:** бәхетле булсыннар, беркайчан сугышлар булмасын. Без күргән авырлыкларны күрергә язмасын,- дигән теләген җиткерде.





# Сәләхов Әхтәри Сәләх улы

1939 елның 13 июлендә Юлбат авылында туган. Гаиләдә 7 бала. **Әтисе карт булу сәбәпле, сугышта катнаша алмый.** Балачак бик авыр елларга туры килде. Без борчак кузаклары, арыш башаклары җыеп тамагыбызны туйдырдык. Аның өчен бер телем ипигә 1 бал калагы бал ягып бирәләр иде,- ди.

Белеме 7 класс. 4 еллык белемне Юлбат башлангыч, 7 еллык белемне Сатыш мәктәбендә тәмамлый. Укырга күтәртмәле чабаталарда йөргәннәр. 1960 елда Сабада тракторлар курсында укый. 1961-66 елларда тракторда эшли. Урак вакытында комбайнер ярдәмчесе булып эшләргә дә туры килә. 1967 елда заправкада эшли. 1967 елдан слесарьлыкка укып кайтып, авыл халкын газ балоннары белән тәэмин итеп тора. Дәүләт биргән бүләкләре кызганычка каршы янгында юкка чыга. Бүгенгесе көндә тормыш иптәше Шәфига апа белән Юлбат авылында яшиләр.



# Шәмсиева (Фәтхриева)
# Флюра Фәтхрахман кызы

1933 елның 13 декабрендә Юлбат авылы Хужин Фәтхрахман белән Шәһәрбану семьясында икенче бала булып дөньяга туа. Сугыш башланганда безнең гаиләдә 5 бала: 4 малай һәм мин. Бөтен авырлык абыем Рухылбаян 1931 елгы, энеләрем Габдрахман, Фатих белән әни җилкәсенә төште. Сугыш башланганда энем Азатка 1 яшьтә юк иде. Әни эштән кайтканда кесәсеннән бер уч ашлык табып хөкемгә тарттылар. Әти сугышта катнашты, **1943 елны сугыштан әйләнеп кайтты.** 1948, 1950 елда Фирая белән Мәүлизә туды.
18 яшем тулгач Казанга китеп төзелештә эшкә урнаштым. 12 ел Казанның “40” нчы заводында эшләдем. 1963 елда Юлбат авылы егете Шәмсиев Рәшит белән тормыш корып җибәрдек. 3 ир-егет үстердем. 1982 елда каты авырудан иптәшем Рәшит вафат булды. Балаларны үстерүдә иптәшемнең абыйсы Һарун, кайнанам Зәйнәп бик нык ярдәм иттеләр. Балалар бернәрсәгә мохтаҗ булмадылар. Лаеклы ялга бик күп еллар “Искра” колхозы конторасында җыештыручы булып эшләп чыктым.

Бүгенге көндә Юлбат авылында 3 улым, 3 киленем 2 оныгым тәрбиясендә яшәп гомер итәм.



# Хуҗин Азат Фәтхрахман улы

1940 елның 1 сентябрендә Юлбат авылында туа. Сугышта әтисе катнаша, **1943 елны туган якларга исән-сау әйләнеп кайта.** Әтисе сугышка киткәндә әнисе итәгендә берсеннән-берсе яшь 5 бала кала. Ат белән салам тарттыру, бер телем икмәк өчен башак, кукуруз җыюлары хәтеренә уелып калган.

Гомер буе “Искра” колхозында башта шофер ярдәмчесе, соңыннан шофер булып эшли. **“Җиңүнең 20 еллыгы” һәм Хезмәт ветераны медальләре** бар.

1970 елда Мишәбаш кызы Гөлчирә белән тормыш коралар. Уллары Әсхәт туа. Хәзергесе көндә Юлбат авылында улы Әсхәт, килене Алсу һәм ике оныгы белән гомер кичерә.

# Каюмова (Фәизова)
# Мәскүрә Фәйзи кызы



1938 елның 1 сентябрендә Калатау авылында туган. Гаиләдә 4 кыз, 1 малай үскәннәр. Дуңгыз фермасында берничә сыер бар иде. Шул сыерларны савып бәрәңге пешереп ашаттык. Пешергән бәрәңгедән үзебезгәдә өлеш чыгара идек. Чөнки ачлык үзәккә үтте,- дип исенә төшерде. **Әтисе сугышка китеп хәбәрсез югалган**. 17 яшендә Йосыф-Алан егете Рашат абыйга кияүгә чыгып 6 бала тәрбияләп үстергәннәр. Гомер буе фермада эшләп лаеклы ялга чыккан. **“Хезмәт ударнигы”, “Хезмәт ветераны” медальләре** белән бүләкләнгән. Бүгенгесе көндә улы Рифат гаиләсе белән Йосыф-Алан авылында яши.



# Рәшитова (Шәмсетдинова)
# Гәмбәр Гәбделбәр кызы

1939 елның 25 августында Тенеки авылында туган. **Әтисе сугышта катнашып, исән-сау кайткан.** Сугышка кадәр үзе генә булган. Әтисе сугыштан кайткач тагын 6 бала дөньяга килгән. 30 ел буе Тенеки башлангыч мәктәбендә пешекче булып эшли. Хәзерге вакытта Тенеки авылында яши.



# Галиев Наил
# Тимергали улы

Әти Тимергали әнием Маһирәгә өйләнеп, 1940 елда вербовка белән Донбасска шахтага китәләр. Авылда тормыш авыр була. 1941 елның 21 июнендә немец Германиясе безнең илгә сугыш башлаганда әни минем белән ике айлык йөкле була. Тиздән немец гаскәрләре Донбасска килеп җитәләр. Сугыш килеп җиткәнче әти, әни белән (вербовка белән килгән башкалар да) кире кайталар. Юлда поездны бомбага тотып ике тапкыр чак үлемнән калалар. Авылга кайткач әтине сугышка алалар. Әни колхозда эшли башлый. Әни ат җигеп атлы эштә эшли. 1942 елның 14 февралендә басудан салам алып кайталар һәм 15 февральдә мин дөньяга килгәнмен. Мин туып ике ай узгач әнине урман кисәргә җибәрәләр. Мине бригадир Мәгерүфә апа имезеп торган. Әни конюшнида атлар караган. Конюшный безнең бакча башында иде. Мин әбидән качып чыгып, үрмәләп тыкрыктан әни янына менгәнмен. Әни - без басудан кайтканда ат койрыгы белән уйнап утыра идең,- дип сөйли иде. Ашарга булмагач атлар ябык, басып тора алмаганнар. Боларны мин хәтерләмим, кечкенә булганмын. Кычыткан салып пешергән ашны болгатып утыра идең,- дип сөйләгәне хәтердә. 1944-45 еллар тирәсе булгандыр урамда олырак малайларның һавадан очып үткән самолетка - “Самолет - әтине кайтар”,- дип кычкырып йөргәннәре томанлы гына хәтердә калган.

**1946 елда әти исән калып сугыштан кайтты.** Сугыштан соңгы еллар коточкыч авыр булды. Черек бәрәңге күмәче ул вакытта бик тәмле иде. Ашка кычыткан, ат кузгалагы салып пешерделәр.

1949-53 елларда Юлбат башлангыч мәктәбендә белем алдым. 1-2 классларда Суфия апа укытты. Ул беренче укытучым. Өченче класста Газзә апа укытты. Уку авыр, мохтаҗлык көчле иде. Язарга дәфтәр юк. Таба алсаң, шәмәхә карандашның сөрмәсен кырып суга салып кара ясый идек. Юньле - башлы кием юк, аякта чабата. 1954-56 елларда Сатыш җидееллык мәктәбендә укыдым. Өч ел җәяү йөреп укыдык. Аннан соң колхозда эшли башладым. Саба урта мәктәбенә барып булмады. Уку түләүле, түләргә акча юк. Әтисе сугышта үлгән балаларга гына уку бушлай иде. 1957 елда Фаттахов Зиннур абый белән “С-4” комбайнында, 1958 елда Сафин Раян абыйда “Стаменец-6” комбайнында салам төшерүче булып,

1959-60 елларда Ганиев Абуталип тракторында прицепщик булып эшләдем.
1962-64 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт иттем. Армиядән кайткач 1965-67 елларда колхозда шофер булып эшләдем. Бер үк вакытта Сатыш кичке урта мәктәбендә укып урта белем алдым. Өч ел һәр көн эштән кайткач кич сәг. 6.00 дан төнге 11.00 гә кадәр Сатышка җәяү йөреп укырга туры килде. 1967-73 елга кадәр колхозның I бригадасына бригадир итеп куелып шул вазыйфаны үтәргә туры килде. Ул елларда колхоз председателе Нигъмәтҗанов Минехан, агроном Һашим абый Нургалиев эшләделәр. Тынгысыз, принципиаль, максат куеп эшли торган кешеләр иде. Алар җитәкчелегендә эшләү тынгысыз, авыр булды. Шул ук вакытта максат куеп эшләгәч эшнең уңай нәтиҗәләре дә күренде. Колхоз күзгә күренеп алга китте, районда алдынгы урыннарны яулады. Игенчелектә икмәк, бәрәңге үстерүдә, терлекчелектә колхоз беренче урында иде. Бу уңышларга ирешүдә минем дә гадел хезмәтем керде. **1970 елда “Хезмәттәге батырлыгы өчен” медале, 1972 елда “Почет билгесе” ордены белән бүләкләндем.**

1974 елда колхозның башлангыч партия секретаре итеп сайланып, 1991 елга кадәр, 18 ел эшләдем. Бу чорда колхозда күп үзгәрешләр булып, күп үсешләргә ирешелде. Колхозда башлангыч мәктәптән башта сигезеллык, соңыннан урта мәктәп ачылды, яңа мәктәп бинасы төзелде. Колхозда культура йорты, техника мастерское, яңа терлек тораклары, амбарлар төзелеп, колхозчыларның тормыш - көнкүреше нык алга китте.

1991-95 елларда колхоз председателе ярдәмчесе, 1996-2002 елларда кабат I бригада бригадиры булып эшләп пенсиягә чыгып ялга киттем.

**Әти сугыштан кайткач** 1946 елда сеңлем Мәшүдә, 1949 елда энем Рафаэль, 1953 елда энем Хаҗинур туды.

1973 елда Мөбәрәкҗан кызы Фәүзия белән гаилә кордык. 4 бала тәрбияләп үстердек.

Безнең буын сугыш чоры балалары - авырлык, мәрхүмлекләргә бирешмичә ил алдында торган бурычыбызны үтәдек. Бабайлар, әтиләр йөзенә кызыллык китермичә эстафетаны яңа яшь буынга тапшырдык дип ышанып калам.

Галиев Наил Тимергали улы.





# Гәләвиева (Хәсәнова) Хөснури Хәсәнҗан кызы

Тенеки авылында Хәсәнҗан һәм Долкамал гаиләсендә 1941 елның 18 июлендә дөньяга килә. Гаиләдә ике бала: абыйсы Мөхәмәткәрим һәм үзе булалар. Әтисе сугыш башлануга сугышка китә. Бу вакытта ул 15 көнлек бала булып кала. Шул китүдән әтисен бүтән күрми. **1942 елда Мөбәрәков Хәсәнҗанның хәбәрсез югалды дигән язу гына килә.** Аның сугышта разведчик булганы гына билгеле. Соңга таба хат белән разведкага киткәндә кесәсеннән алып калынган фотосүрәтен хат белән әнисенә салалар. Хөснури апа сугыш вакытында сабый булгач, ул вакытларны бик хәтерләми. Үсә төшкәч колхозга төрле эшкә йөри башлый. Чеби фермасында, сарык фермасында, гомумән колхозда нинди эш бар берсен дә авырыксынмыйча бер көн эштән калмыйча эшли. 1962 елда Тенеки авылы егете Гәләвиев Гаяз белән кавышып яши башлыйлар. 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Сонгы елларда “Искра” күмәк хуҗалыгында терлекчелектә эшли, сыер савып лаеклы ялга чыга. Эш дәверендә алдынгылар рәтендә була. Бик күп мактау кәгазьләре бар. Бүгенге көндә ире Гаяз белән 53 ел Тенеки авылында гомер итәләр.





# Гәләвиев Гаяз
# Гәләви улы

1939 елның 25 сентябрендә Тенеки авылында Гәләви һәм Хөсниямал гаиләсендә дөньяга килә. Гаиләдә 6 бала булалар, 3 туганы бик кечкенә вакытта ук вафат булалар. Апасы Миңнехаҗәр белән абыйсы Нуретдин олы яшкә җиткәнче яшиләр. Сугыш башланган вакытта 2 яшьлек сабый гына булганлыктан хәтерләми.

**1946 елның җәй аенда әтисе Гәләви сугыштан исән-имин әйләнеп кайта.** Бу вакытта аңа 7 яшь була. Сугыштан кайткач әтисе төрле эштә эшли: тимерчелектә, колхозда, кайда авыр эш була берсеннән дә калмый. 1967 елда бакыйлыкка күчә.

Гәләвиев Гаяз яшьүсмер вакыттан колхозда төрле эшләргә йөри башлый. 1965 елда Саба районы эчке эшләр бүлегенә шофер-милиционер булып эшкә урнаша. Эшләү дәверендә үзен яхшы яктан гына күрсәтә. Төрле грамоталар, медальләр белән бүләкләнә. Эш дәверендә дежурный ярдәмчесе булып күчә, 1991 елда лаеклы ялга чыга. Хезмәтен югары бәяләп “Отличник –милиции” һәм “Хезмәт ветераны” дигән медальләр белән бүләкләнә.

Тенеки авылы кызы Хөснури белән гаилә корып 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Балаларының һәрберсенең үз тормышы. Бүгенге көндә 53 ел матур гаилә булып, Тенеки авылында гомер кичерәләр.



# Хафизов
# Нурмый Хафиз улы

1940 елда Юлбат авылында туган.

Сабый булу сәбәпле, сугыш чорын хәтерләми. Ләкин ул Чернобыль АЭС тында катнашкан сугыш чоры баласының берсе. Безнең белән шул хәтирәләре белән уртаклашты.

. Ул 1986 елның 14 сентябрендә китә.

- Комбайнда эшләгән вакыт. Комиссариаттан чакыру килде, - дип искә ала. Карышып тормадык киттек. Без 6 айга алынган идек. Барысы 82 көн булдык. Станциягә баргач андагы хәрабәләрне күреп шаккаттык. Тирә-юньдә тереклек юк, кошлар очмый. Безнең яшәү урыны Чернобыльдән 65 км. читтә, Иванково дигән шәһәрдә иде. Мин аварияне бетерүдә катнашучы техниканы туплап тордым. Станциягә керер алдыннан саклагыч киемнәр бирәләр, авыз-борынны исә марлядан ясалган повязка белән генә каплыйсың. Нурланышның дозасы аның алсулана башлавыннан да күренә. Артык тоткарлансаң, рация аша, срогың тулды, чык, дип шунда ук дәшәләр, - дип сүзен тәмамлады.

Рабига апа белән 3 бала тәрбияләп үстерделәр. Барысыда тормышлы. Ләкин тормыш иптәше Рабига апа гына иртә гүр иясе булды. Хәзергесе көндә Юлбат авылында гомер итә.



# Кадыйрова (Хәсәнова) Сания Хәсән кызы

1935 елның 15 июнендә Саба районы Сабай авылында дөньяга килә. Әтисе Хәсән әнисе Мәхүп. Әтисе сугыш башлануга сугышка китә. Сугышта командир була. **Шул китүдән хәбәрсез югала.** Балачак елларын бик авыр булды. Ачлык, ялангачлык үзәккә үтте. Пичкә ягарга утын юк, кышлар бик салкын килде, күп кешеләр өйдә тордылар. Өйдә әби белән бабай, әни көне буе эштә. Безне шулар карады. Сабай авылыннан Мишә елгасы ага, бабай шуннан балык тота. Бер урыс тимерчесе бар иде авылда. Кысла балыгын шул тимерчедән ипигә алыштырып ала иде,- дип искә ала. Гаиләдә өч бала: сеңлесе Сәлимә һәм энесе Юныс була. Энесе күп еллар элек вафат була. Сеңлесе Теләчә районында гомер кичерэ.

Сабада пекарня да ипи пешерүдә эшли. 1958 елда Юлбат егете Гәптелхәбир белән танышып гаилә корып яши башлыйлар. Биш бала тәрбияләп үстерүләр. Юлбат авылына килгәч фермада терлекчелектә эшли. Шуннан лаеклы ялга чыга. Эшләгән чорда хезмәтен югары бәяләп “Хезмәт ветераны” медале белән бүләкләнә. Мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары да бар.Тормыш иптәше Гәптелхәбир 1998 елда бакыйлыкка күчә.

Бүгенге көндә Теneки авылында кызы Гөлсинә гаиләсендә гомер итә.



# Маликова (Мусина) Венера Җиһанша кызы

“ Мин 1938 елның 4 ноябрендә Ак-Бигәнәй авылында Әкрамниса белән Җиһанша Мусиннар гаиләсендә дүртенче төпчек бала булып дөньяга килгәнмен. Мин тугач, әтиемне Калатау авылына колхоз председателе итеп билгелиләр. Шул сәбәпле, без Калатау авылына күченеп килгәнбез.

1941 елның 22 июнендә сугыш башлана. Минем эти белән бердәнбер күңелгә уелып калган вакыйга - газиз әтиемне дәһшәтле Сугышка озату. Сугышка китәсе көнне әтием тупсага утырып, мине алдына утыртып: “Каракаем”,- дип яратуын бүгенгедәй хәтерлим. Борчылуын басар өчен тәмәке тартуы да күз алдымда. Һәм шул тәмәке очкыны ялгыш минем ботыма төшеп, борчак кадәр эз калдыра. Шул эз әтиемнең истәлеге булып бүгенге көндә дә җылытып тора. Әнием Әкрамнисадан эти белән бәйле 2 хат килүен беләм. Беренче хат: Днепр буенда каты бәрелешләрдә яраланып, күт битемне алдырдым, госпитальгә салдылар, ә икенчесе **Мусин Җиһанша - “Билгесез югалды” ( үлгән елын төгәл хәтерләмим) дигән**. Күрше йортта яшәүче авылдашыбыз Нәҗип абыйның туганнарына язган хатыннан тагын шуны белдек: “Эшелоннар кара - каршы очрашканда, әтиегезне күрдем. Бер-беребезгә куллар болгаштык. Сөйләшеп торырлык мөмкинлек булмады”,- дип уфтанып язган була ул.

Әтиемнең, “Хәбәрсез югалды”, - дигән хатыннан соң минем әтиле балачак тәмам. Әниемнең: “Башта Белка, Феска дигән атларыбызны алып киттеләр сугышка, 3 көннән соң мәңгелеккә дип әтиегезне озатканмын сугышка”, - дип уфтанып утыруын еллар үткән саен тирәнрәк аңладым. Шулай итеп, сугыш вакытындагы һәм сугыштан соңгы авыр вакытларны үз җилкәмдә тоеп, олы тормыш юлына аяк бастым. Яраткан егетем Гаптрафыйк белән тормыш корып, 5 бала тәрбияләп үстердек. 12 ел урман хуҗалыгында яшелләндерү эшендә эшләдем. Соңрак колхоз эшләрендә катнаштым, фермада сыер саудым. 5 бала табып үстергән өчен “Ана даны” медаленә лаек булдым, тырыш хезмәт өчен “11 нче бишьеллык ударнигы” билгесе белән бүләкләндем.

Бүгенге көндә Йосыф-Алан авылында улым Альберт, киленем Гөлнара тәрбиясендә гомер кичерәм.”



# Мансурова (Әһлиева) НурانияӘһли кызы

“ Мин 1937 елда Тенеки авылында икенче бала булып дөньяга килгәнмен. Без сугыш чоры балалары. Әти сугышка киткәндә миңа 4 яшь, абыйга 7 яшь булган. Без бик тилмереп үстек. Әнинең эшкә киткәнен белми йоклап кала идек, ә кич тагын кап-караңгыда кайта иде. Ә кайтканын апый белән йокламыйча көтеп ала идек. Чөнки без бик ач, ач булгач йоклап та булмый. Әни әтинең киемнәрен каядыр алып китеп бәрәңгегә алыштырып та кайта иде. Әни 2 тапкыр: берсендә 3 ай, берсендә 4 ай безне әбидә калдырып, окоп казырга китте. Әби безне бик кадерләп бишмәтләргә төреп йоклата иде. Иртә белән торгач мин әбидән әни кайтмадымы,- дип сорыйм да, әби юк шул балакаем күренми әле кайтыр-кайтыр дия иде. Әби чыгып киткәч апый мине орыша, һаман сорама, әнә бит әби дә сагынган дия иде. Хәзер үзем әби булгач аңлыйм. Ул безне җәлләп елаган икән. Әнинең соңгы тапкыр кайтканда чәй эчмичә чабатасын сала алмады. Чөнки чабата аякка ябышкан булган. Без ашамаган үлән калмады: кычыткан, алабута, балтырган, кәҗә сакалы, кузгалак, какы, әнис. Җәйгә чыксак хәйран тамак туя иде. **Әти сугыштан 1945 елда бер аяксыз булып кайтты.**

7 классны Мәртен мәктәбендә укыдым. Әти сөт җыя иде. Ул үлгәч сөт җыю миңа калды. Иртүк торып сөт җыям, аны ат белән май заводына менгерә идем. Берсендә ат өйдән чыгуга чаба башлады. Һич тыяр хәл юк. Мин атны дөрес җикмәгәнмен икән. Юныс исемле абый кабат туарып җигеп бирде. Рәхмәт яугыры. Сөттән төшәм дә сеңлем Фираяны утыртып урманга утынга барам. Почтальон булып та эшләдем. Сатыштан Хаҗиева Фатыйма апа алып менә иде. Мин таратам. Бала вакыт эләкмәде дә. Бер яшьлек күрми гомер үтте дә китте.

1956 елда апый армиядән кайтты. Паспорт алып бирде дә. мин Кизлярга киттем. Столовайда кухня эшчесе булып эшләдем. Аннан мине шахтерлар ашханәсенә күчерделәр. Эш бик авыр иде. Бер елдан отпускага кайттым. Әни рәхмәт төшкере кабат җибәрмәде. Монда крахмал заводына эшкә урнаштым.

1960 елда Юлбат егете Саматка кияүгә чыгып, 3 бала тәрбияләп үстердек. Балаларым барсы да тормышлы. Хәзерге вакытта улым Фидаиль гаиләсендә гомер кичерәм.”, - дип тәмамлады истәлекләрен Нурания апа.





# Мифтахов
# Хәнәфия Садрый улы

1943 елның 28 июнендә Саба районы Юлбат авылында туган.
Сугыш елларын ук бик төгәл хәтерләмәсәм дә сугыштан соңгы еллар барлык авырлыгы белән һәр күзәнәккә сеңеп калган. Өс – баш начар иде,күтәртмәле чабаталар киеп урман да кистек,кырда да эшләдек. Ашау өчен саман сугарга йөрдек. Саман сугу – кызыл балчыкка салам кушып, кирпеч сыман формага салу.
Гаиләдә биш бала туганбыз. Яхъя, Зәкәрия,Сәрия,мин һәм Мөршидә. Тик Яхъя, Зәкәрия абыем һәм Сәрия апам сабый чакта ук вафат булганнар.
**Сугыштан әти авыр яралар белән әйләнеп кайтты.** Озак еллар аягындагы яралары төзәлмичә азаплады.Авылда, колхозда тракторда һәм башка эшләрдә хезмәт куйды.
Мин туган авылымда башлангыч мәктәпне, Сатыш авылында белем алып, 1958 нче елда җидееллык мәктәпне тәмамладым. Комбайнчы ярдәмчесе булып эшләдем. 1961 нче елда военкомат буенча автошколга укырга җибәрделәр. 1962 елның 20 маенда әлеге мәктәпне тәмамлап Ихсанов Равил абый белән машинада эшләдем. 1962 нче елның 12 ноябрендә армия хезмәтенә алындым. 1965 елның 13 декабрендә туган ягыма әйләнеп кайттым. Кичке 11 еллык мәктәпне тәмамладым. 1967 елда Тенеки авылы кызы Гөлчирә Шамсетдин кызы белән тормыш корып җибәрдек. Шул елны Казахстанга эшкә чыгып киттем. Олы кызыбыз Раушания шунда дөньяга килде. 1970 елда туган якка әйләнеп кайттык. Уртанчы кызыбыз Рәйхана туды. 1978 елда кече кызыбыз Рәмзия дөньяга килде. Шул кайтудан гомер буе колхозда шофёр булып хезмәт куйдым. Хезмәтемне яратып, тәм табып эшләдем. Бик күп төрле мактау грамоталары белән бүләкләндем. **Хезмәт Ветераны булып пенсия ялына чыктым.** кияүләребез, оныкларыбыз тәрбиясендә тыныч тормышка шөкер итеп, матур гына гомер кичерәбез.

# Габделхаева ( Хуҗина) Нажия Хаҗи кызы





1937 нче елның 10 июнендә Саба районы Юлбат авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне Юлбат мәктәбендә ала. 5нче класста укуын Сатыш мәктәбендә дәвам иттерә. Ачлык, мохтаҗлык алга таба укуын дәвам иттерергә мөмкинлек бирми.

**Әтисе Бөек Ватан сугышында катнашкан, ләкин кире туган якларына әйләнеп кайту насыйп булмаган.**

Хезмәт юлын Саба яшелчә киптерү заводында башлап җибәрә. Казан шәһәренә җибәрелеп, Казанка елга буйларын цементлау эшләрендә катнаша. Кияүгә чыкканнан соң эшчәнлеген колхозда дәвам иттерә.1992 елда лаеклы ялга чыга. Бүгенге көндә Юлбат авылында гомер кичерә.



# Рахимуллин Миннегали Төхбәтулла улы

1942 елның 12 нче мартында Юлбат авылында колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе - Төхбәтулла, әнисе – Әнвәр колхозчылар була. Алар өч бертуган: Мәдәния апа, абыйсы Даниял .

Әтисе турында әнисе сөйләгәннәрдән генә белә. **1941 нче елда сугышка киткән һәм хәбәрсез югалган.** Әниләре өч баланы ялгыз үстерә.

Ачлык, авыр еллар, яшьтән эшкә чыктык, 7 класстан колхоз эшенә йөрдек,- дип сөйли. 30 ел “Искра” колхозда кладовщик булып эшләп лаеклы ялга чыга. Тырыш хезмәтләре өчен ”Двадцать лет победы в Великой Отечественной войне 1941-1945гг” - 5 декабрь 1965, “За доблестный труд”, В ознаменование 100-летия со дня рождения В.И.Ленина - 1 апрель 1970 ел, “Ударник девятой пятилетки”- 30 январь 1976 ел, ”Победитель социалистического соревнования 1977 года” - 10 февраль 1978 ел, ”Победитель социалистического соревнования 1980 года” - 4 февраль 1981ел, ”Ударник одиннадцатой пятилетки” - 11 декабрь 1982 ел, 24 февраль 1974 елда“Ударник Коммунистического Труда” медальләре белән бүләкләнә.

1972 нче елда Шытсу кызы Мөсәллия Фәләхетдин кызы белән тормыш корып дүрт бала тәрбияләп үстерделәр.Уллары Тәлгать,Таһир һәм кызлары Тәнзилә,Рәзинә. Бүгенге көндә Юлбат авылында кече улы Таһир гаиләсе белән гомер итә.



# Фәтхуллина (Гәләвиева)
# Гайшә  Гәләви кызы

1938 елның 29 нчы маенда Алан-Җөри авылында дөньяга килә. Алар гаиләдә 11 бала булалар. **Әтисе сугышка бармаган.** Ул 45 яшендә вафат булган.

Фәтхуллина Гайшә 7 класс белем алган. Башта 13 ел фермада, аннары Шәмәрдәндә пекарняда эшләгән.Сугыш елларында, киндердән күлмәк, чабата үргәннәр. Ачлык елларында кычыткан ашы, алабута ипие ашаганнар. Аларга Мишә елгасы якын булган. Анда балык тотканнар, шуны пешереп ашаганнар.
Шуның белән исән калганнар.1966 елда Юлбат авылына Гәптевәли абыйга кияүгә чыга. Гәптевәли абый белән 5 бала тәрбияләп үстергәннәр. Хәзерге вакытта 3 кызлары Казанда тормыш итә,  уллары авылда яши. “Искра” колхозында төрле эштә хезмәт куя. 1981 елда **“Ана даны”, “Ветеран труда”медальләре** белән бүләкләнә. Хәзерге көндә лаеклы ялда. Гәптевәли абый белән 50 ел бергә гомер иттәләр,  Юлбат авылында яшиләр.



# Фәтхуллин Гәптевәли Гәбдерәүф улы

1938 елның 2 июлендә Юлбат авылында Гәбдерәүф белән Мәрьямбикә гаиләсендә 4 нче бала булып дөньяга килә. Гаиләдә өч малай, ике кыз булган. Әтиләре Гәбдерәүф сугыш кырында мина шартлап балчык астында күмелеп кала. Иптәшләре табып алып госпитальга озаталар. Ул анда 6 ай буе дәвалана**. 1942 елда контузия алып Юлбат авылына кайта.**

Гәптевәли абый 1963 елдан алып 1991 елга кадәр Сабада “Дом быта” да печник-футеровщик булып, 1991-1998 елга кадәр Юлбат урта мәктәбендә кочегар булып эшли. **1967 елда аңа “Отличник службы быта**” дигән күкрәк билгесе белән, **1971 нче елда “Ударник коммунистического труда”** дигән медале белән бүләкләнә. **1991 елдан “Ветеран труда".** Авылыбыз уртасында балкып утыручы мәчетебезнең нигезен салучы да ул. Мәчеттә 23 ел мулла булып хезмәт итә. Хәзергесе көндә тормыш иптәше Гайшә апа белән Юлбат авылында гомер итәләр.



# Ханипова (Муллиева) Нурия Мулли кызы

1938 елның 2 октябрендә Тенеки авылында колхозчы гаиләсендә туган. 1947 елда Тенеки башлангыч мәктәбенә укырга керә. Анда 4 класс укый. Соңыннан Мәртен җидееллык мәктәбен тәмамлый. Сугыш һәм аннан соңгы елларда тормышлары бик авыр булган. Әтиләре сугышка кадәр 1940 елда вафат була. Сугыш вакытында гаиләдә 3 бала була. Мәктәп бетергәннән соң колхозда төрле эшләрдә: комбайнда салам төшерүдә, урманда агач утыртуда эшли. Сабада яшелчә киптерү заводында 10 елга якын хезмәт куя. “Искра” колхозында сыер савучы булып лаеклы ялга чыга. 1964 елда кияүгә чыгып 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Бүгенгесе көндә Тенеки авылында улы Альберт гаиләсе белән яши.



# Гомәров Мөҗәһит Госман улы

“1938 елның 5 августында Госман белән Мәүтүмә гаиләсендә 2 нче бала булып дөньяга килгәнмен. Без гаиләдә 8 бала. 1945 елда Тенеки мәктәбенә укырга кердем. 4 классны Тенеки, 7 классны Мәртен мәктәбендә тәмамладым. 1957 - 60 елларда Армиядә хезмәт иттем. 1960 елда Сөнгатуллина Шәмсениса белән тормыш корып җибәрдек. Һәм көз аенда Пермь өлкәсенә чыгып киттек. Анда шахтер булып эшләдем. 2 бала тәрбияләп үстердек. 1996 елда кабат туган якларга әйләнеп кайттык. Хәзерге вакытта Тенеки авылында яшим.”



## Шакирҗанова (Шәяхметова) Тәнзилә Фазыл кызы

1940 елның 7 январенда Мамадыш районы Тәкәнеш авылында дөньяга килә. Гаиләдә бердәнбер бала була. Әтисе башта Финляндия, аннан соң Бөтендөнья сугышында катнаша. **Кызганычка каршы хәбәрсез югала.**

Тәнзилә апа эшен фермада эшләп башлый. 1976 елда мәктәптә эшләп ала. Һәм кабат фермада эшләп пенсиягә чыга. Фермада эшләгән дәвердә Мактау грамоталары белән бүләкләнә.

Шакирҗанов Миннегәрәй абый белән тормыш корып, 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта Теneки авылында яши.

## Шакирҗанов Миннегәрәй Муллагаян улы

1940 елның 16 ноябрендә Тенеки авылында туа. Гаиләдә 2 бала: абыйсы Миннәхмәт һәм ул. **Әтисе сугышта хәбәрсез югала.**

“Тормышның иң авыр вакытына туры килгән  балачаклары.  Миннегәрәй абый 5 яшьтән эшли башладым,- дип сөйли. Ачлыкка да тилмердек. Әни басудан черек бәрәңге алып кайтса, абый белән сөенә идек,- ди. Әти белән урманга утынга баргач трактор таптый язды. Кырыйга гына чыгып калдык, чананы таптап китте,- дип хәтирәләрен яңартты.

1962-65 елларда 3 ел Совет Армиясе сафларында хезмәт иткән.  Тәнзилә апа белән тормыш корып,  3 бала тәрбияләп үстерәләр. Бүгенге көндә Тенеки авылында яши.



# Сафин Гыймран Нәкыйп улы

1939 елның гыйнварында Йосыф-Алан авылында туганмын. 4 класс тәмамладым. 1953 елда Түбән Шытсу җидееллык мәктәбенедә 7 класс бетердем. Шуннан соң 3 ел колхозда эшләдем. Сугыштан соңгы авыр еллар, укырга мөмкинлек булмады. 1956 - 57 елларда Усадта тракторчылар мәктәбендә укыдым. Шуннан соң 1980 елга кадәр “Искра” колхозында механизатор булып эшләдем. 1990 елда төзелешләрдә эшләп лаеклы ялга чыктым. 4 бала үскәннәр. **Әтисе сугышта катнашкан. Ләкин кире әйләнеп кайтмаган. 1941 елда хәбәрсез югалган.** Флера Гәйфетдин кызы белән тормыш корып 3 бала тәрбияләп үстердек. Хәзерге вакытта Йосыф-Алан авылында яшиләр.

# Сафина (Гәйфетдинова) Флера Гәйфетдин кызы



1938 елның 27 маенда Чәбки - Саба авылында тудым. 1954 елда Саба мәктәбендә 8 классны тәмамладым. 1955 елда Югары - Ослан районында бухгалтерлар курсында укыдым. Укып бетергәч Саба сельпосында бухгалтер булып эшләдем. 1959 елда Йосыф - Алан клубына мөдир булып килдем. Клубта эшләгәндә Мактау грамотасы белән бүләкләндем. 1973 елдан “Искра” колхозына сыер савучы булып күчтем. 23 ел сыер савучы булып эшләп 1993 елда лаеклы ялга чыктым. Тормыш иптәшем Гыймран белән 3 бала тәрбияләп үстердек. Бүгенгесе көндә Йосыф - Алан авылында яшибез.



# Хәлиуллина (Зәйнуллина)
# Хажәр Зәйнулла кызы

1934 елның 6 июлендә Туктар авылында туган. **Әтисе сугышта катнашып кабат әйләнеп кайткан.** Бик яшьли эшли башлый. Дуңгыз фермасында эшләгәндә бәрәңге пешерә идек. Шул кайнар бәрәңгене аяк белән изгәндә аяклар пешә торган иде,- дип искә алды. 27 яшенә кадәр фермада эшли, аннан Йосыф-Алан авылына Халиулла абыйга килен булып төшә. 2 бала тәрбияләп үстегәннәр. Хәзерге вакытта оныгы тәрбиясендә Йосыф-Аланда яши.



# Хәмитова (Гәлиәхмәтова)
# Махруза Гәләхмәт кызы

1938 елның 5 ноябрендә Юлбат авылында туган. Семьяда 4 бала булганнар. **Әтиләренә сугышта катнашып туган якларына кайту насыйп булган.** 1954 елда Шәмәрдәндә тегү цехында эшли башлаган. Аннан соң сәүдә системасында эшләгән. 1964 елда Юлбат авылы егете Хәмитов Фоат белән тормыш коралар. 3 бала үстергәннәр. Җирәм җирләр күтәрүдә катнашканнар. Хәзерге вакытта Юлбат авылында яши.



# Хафизова (Халиуллина) Гәүһәрия Халиулла кызы

Мин 1941 елның 28 мартында Йосыф - Алан авылында туганмын. Әти сугышка киткәч әнигә тормыш алып барырга авыр калган. Әле дә хәтердә, ашарга, кияргә юк. Бер көнне әни каяндыр он алып кайтты. Без елыйбыз. Оннан камыр ясап бетергәнен түзеп көтеп тора алмыйбыз. Тамак ачу шундый көчле. Әни тәлинкәгә 1-2 кашык он салып (он арыш белән алабута катыш), яртышар чокыр сөт бирде. Онны ялап, сөтне эчеп куйгач тынычландык. Ә аннан мичкә ягып күмәч пешерде.

Безнең гаиләдә 4 бала: 2 абый, апа һәм мин. Әти сугышка киткәндә олы абыйга 9 яшь, кече абыйга 7 яшь, апага 5 яшь, миңа 3 ай булган. Әти 1941 елның июнь аенда киткән. 1 ел Казанда эшләп өйгә кайткан. Бер атна торгач 1942 елның июль аенда кабат киткән. Барып җиткәч хат язган. Мин сугышның бик каты булган урынында. Белмим исән калырмынмы? Фатыйма бәхил бул. Балаларны тәрбияләп үстерергә тырыш инде дип язылган була. Яңадан хәбәр килми. Ә мин әтине белмим. **Әти хәбәрсез югалган.**

Минем балачак дустым, Фирая, бездән ерак түгел. Шуларга уйнарга барам. Аның 2 сеңлесе, 1 энесе бар. Әтиләре Рәшит абый бригадир булып эшли. Урамда уйнаганда әтиләрен ат белән кайтып килгәнен күрделәр. Әти кайта дип каршысына йөгерделәр. Миндә барам. Әз генә бардым да туктап калдым. Рәшит абый кил,- дип чакырды. Мине күтәреп арбаның уртасына утыртты. Шунда сөенүләрем. Өйгә кайткач әни нигә әти кайтмый ул, - дип еладым. Әни кайтыр-кайтыр дип мине кочаклап елаганы әле дә хәтердә. Әниләре Мәдинә апа мич тутырып ипи пешерә. Өйләренә кергәч миңа ипи бирә. Аның тәме әле дә авызда.

40 ел фермада эшләдем: башта бозаулар карадам, аннан сыерлар саудым. I урында күп еллар булдым. Грамоталар белән бүләкләндем.

Йосыф-Алан егете Хөрмәт белән гаилә корып 4 бала тәрбияләп үстердек: 2 кыз 2 малай.

Хәзерге көндә улым Хәлим, киленем Гөлсинә, оныкларым Хәдис, Хәйдәр белән тыныч тату гаиләдә  Йосыф-Алан авылында яшим., - хәтирәләре белән уртаклашты Гәүһәрия апа.



# Гайфуллина (Хәмитова) Мәгъфия Хәмит кызы

1934 елның 10 февралендә Саба районы Юлбат авылында дөньяга килә. Алар гаиләдә 4 бала булалар. Сеңлесе белән абыйсы бала чакта ук вафат булалар, энесе олы яшькәчә яшәп вафат була.

Сугыш башланганда Мәгъфия апага 7 яшь була**. Әтисе сугышка 1941 нче елда китә, кире әйләнеп кайтмый**. Шул чордан истә калган вакыйгаларны әтисен сугышка озату һәм сугыш бетү хәбәрен ишетү,- ди.

Мәгъфия апа 5 сыйныфны бетергәннән соң колхозда эшли башлый. Төрле эшләрдә эшләгән: ике ел фермада тавык караган, агач утыртуга, чүп утауга йөргән, комбайнда да эшләгән. Агач кисүгә дә барган.

1955 нче елда, 21 яшендә Гайфуллин Вәлимөхәммәт Гайфулла улына тормышка чыга. Матур гына гаилә коралар. 5 бала: 5 ир-ат үстерәләр. Бишесе дә хәзерге вакытта гаилә корып яшиләр. Мәгъфия апа 9 онык үстерә.

**II дәрәҗәдәге “Ана медале” һәм “Хезмәт ветераны” медале белән бүләкләнә.**

Хәзергесе көндә төпчек улы Хәким гаиләсендә гомер кичерә.



Президент Республики Татарстан Указ от 31.05.99
Наименование государственного органа принявшего решение о присвоении звания ветерана

УДОСТОВЕРЕНИЕ

Серия А № 266376

Гайфуллина
фамилия
Магфия
имя
Хамитовна
отчество

Предъявитель настоящего удостоверения имеет права и льготы, предоставляемые на условиях и в порядке, установленных статьями 22 и 23 Федерального закона "О ветеранах"

Ветеран труда
полное наименование соответствующей категории ветеранов

УДОСТОВЕРЕНИЕ БЕССРОЧНОЕ ДЕЙСТВИТЕЛЬНО НА ВСЕЙ ТЕРРИТОРИИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Дата выдачи "14" июня 1999 г.





От имени Президиума Верховного Совета СССР Указом Президиума Верховного Совета Тат. АССР 31 октября 1972 г.

награждена медалью

„Медаль материнства"

II степени

Секретарь Президиума Верховного Совета

20 апреля 1973 г.

И № 755206

# Ибатуллин Сөләйман Ибәтулла улы



1938 елның 14 мартында Юлбат авылында колхозчы гаиләсендә туган. Алар семьяда 6 бала үсә. Сугышка кадәр дүртесе, сугыштан соң икесе туган. Әтисе Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыш вакытын бик авырдан хәтерли, чөнки бәләкәй булган. Сугыш вакытында бик авыр булуын, ашарга булмавын әнисенең сөйләгәннәреннән әйтә.

Сөләймән абый Йосыф-Алан авылы кызы Мәгфүрә апа белән тормыш корып 13 бала тәрбияләп үстерделәр. Хәзерге вакытта Юлбат авылында яши.

# Дәүләтшина Рәшидә Мансур кызы



1941 елның 25 августында Сабада туган. Сугыш вакытында гаиләдә 3 бала булганнар. **Әтисе сугышта катнашып, исән-имин әйләнеп кайткан.** Сугыштан соң тагын 2 балалары туган. 13 яшеннән эшли башлаган. Комбайнда салам төшерүче, комбайнер ярдәмчесе, почтальон, торфта, Кукмара тегү фабрикасында, Сабада яшелчә киптерү заводларында да эшләгән. Соңыннан Юлбат мәктәбендә җыештыручы булып эшләп лаеклы ялга чыккан. Тормышка чыкмаган. Хәзергесе көндә Юлбат авылынга гомер итә.



# Фәләхиева (Батыршина) Зәмзәмия Мөбәрәкҗан кызы

1941нче елның 13нче февралендә Тенеки авылында дөньяга килә. Тенеки башлангангыч мәктәбен, Мәртен җидееллык мәктәбен тәмамлагач “Искра” колхозында терлекчелектә хезмәт куя. 1941нче елда сугыш башланып әтисе Батыршин Мөбәрәкҗан Батырша улын фронтка алганда ул 5 айлык бала булып бишектә кала. Әнисе Фәйрүзә барлык башка хатын-кызлар кебек үк көнне-төнне белмичә басу-кырларда тырышып эшли. Хезмәт бик авыр була. Аларны хәтта урманга агач кисәргә җибәрәләр. Хатын кыз хезмәте белән берлектә барлык ир-ат хезмәтен башкаралар. **1942нче елда әтисе Мөбәрәкҗанның хәбәрсез югалганлыгы турында хат килә**. Шунлыктан Зәмзәмия әтисен күрми кала. Бүгенге көндә Тенеки авылында кече улы Фәнил гаиләсендә яши.



# Ибраһимова (Халикова) Нурия Халик кызы

1939 елның 28 июлендә Юлбат авылында туган. Гаиләдә 3 бала үскән: 1 малай, 2 кыз.
1956-1967 елларда кошчылык фермасында, 1967 -1978 елларда умартачы, 1979-1989 елларда “Искра” колхозында бозау караучы булып эшләгән. Яз-көз айларында чәчүлеккә чыгару өчен симәнәләр агулап кырга чыгарып торганнар. Эш дәверендә мактау грамоталары һәм “Коммунистик хезмәт ударнигы” значогы белән бүләкләнә. Хәзергесе көндә кызы Равия гаиләсе белән Юлбат авылында яши.



## Гәлләмова (Кашапова) Рәмзия Кашаф кызы

1933 елның 3 июлендә Мәртен авылында туган. Хәзерге вакытта Тенеки авылында яши.




## Туктарова (Тимергалиева) София Валиевна

Я родилась 8 сентября 1940 года в Казани. Я была одна у мамы. **Папа не вернулся, умер на войне.** 57 лет жила в Казани. Потом переехала жить в деревню Юсуп-Алан. 39 лет работала в пороховом заводе. Трудовые награды потеряна.



## Гәлләмов Гилемхан Гәлләм улы

1933 елның 10 февралендә Юлбат авылында туган. Хәзерге вакытта Юлбат авылында яши.



# Газетдинов Нуретдин Газетдин улы

Туганурыны:   Саба районы Юлбатавылы
Туган  көне: 10.01.1935
Белеме: 4 класс
Гаилә составы: 1 кеше
Гомуми   эш стажы, соңгы эш урыны һәм эш вазифасы :  42  ел, “ Искра” колхозында балта остасы, төрле эштә.
Социаль статус: лаеклы ялда.

Гаиләдә 4 бала: 3малай, 1 кызтуа.  ӘтисеБөек Ватан сугышында катнаша. Балачагында  бик исендә калган вакыйга: “Көтү көттек, көлтә бирдек, симәнә чыгардык.Үсмер чакта бар эшне дә рәттән эшләдек,- дип искә төшерде. 1954 елда армия сафларына алына. 1952-1994 елларда “Искра “ колхозында эшли.
Хәзерге вакытта Юлбат авылында яши.

# Мусина (Хәмитова)
# Гәмбәр Хәмит кызы

1939 елның 4 июлендә Йосыф - Алан авылында туа. Ашарга кысан. Түбән Шытсуга җәяү йөреп укыган. 7 класс бетерүгә фермада сыер сауган. Кул белән саудык, ашатырга юк. Әнисе дә авырган. Орчык кадәр гәүдә белән апра, салам, ящик белән сенаж - силос ташып ашата идек,- дип хәтирәләре белән уртаклашты Гамбәр апа. Семьяда бер бала булган. 1942 елда әтисе сугышка киткән. **Украинада үлеп калган.**

1962 елда Юлбат авылы егете Мусин Миңлебайга кияүгә чыккан. Бер кыз үстергән. Хәзерге вакытта Йосыф-Алан авылында яши.

# Хуҗина (Имамиева)
# Нурия Имами кызы

1940 елның 20 октябрендә Йосыф-Алан авылында туган. 7 класстан укыганнан соң фермада бозау караган. Соңыннан сыер караучы булып пенсиягә чыккан. **Әтисе сугышта катнашып, исән-сау кайткан.** Бүгенге көндә Йосыф - Аланда улы Айрат гаиләсе белән яши.

# Сираҗиева (Йосыфҗанова)
# Тахирә Шакирҗан кызы

1935 елның 3 февралендә Байлар Сабасында туган. Гаиләдә 3 бала: 2 абыйсы һәм үзе. 7 яшьтән әтисез, 10 яшьтә әнисе дә үлеп, ятим кала. Әтисе сугышта катнаша, **1943 елда хәбәрсез югала.** 11 яшьтә Лаешка урман кисәргә бара. 20 яшьтә район больницасына эшкә урнаша. 23 яшендә Йосыф-Алана авылына кияүгә чыгып 2 кыз бала үстерә. Сыер савучы эшли башлый. Хәзерге вакытта Йосыф-Алан авылында яши.

# Дәүләтшина (Кәшипова) Илһамия Кәшип кызы

1942 елның 28 январендә Тенеки авылында дөньяга килә. Гаиләдә 6 бала, шуның икесе яшьтән үлгәннәр. Әтисе сугышка киткәндә әнисе 4 бала белән калган. Ләкин кире туган якларына әйләнеп кайтырга насыйп булмаган, 1941 елның январенда вафат була. Шулай итеп әнисе 4 бала белән тол кала.

Сугыш вакытында бик авыр булды. Ашарга булмады. Кычыткан ашап үстек. 12 яшьтән эшли башладым. 8 ел амбарда эшләдем. Эшләгән вакытта кесәгә икмәк салып кайта идек. Шул икмәктән ипи пешереп ашата иде әни, - дип искә алды Илһамия апа. Калган озак елларын кибеттә эшләп пенсиягә чыккан. 1967 елда Тенеки авылы етете Дәүләшин Мөбәрәкша абыйга кияүгә чыккан. 3 бала тәрбияләп үстергәннәр. Бүгенгесе көндә Тенеки авылында яши.

Яшьләргә теләгем шул: сугышлар булмасын, шушындый матур тормышта бәхетле булсыннар.

# Нуретдинова (Җәләлиева) Фирая Рәшит кызы

1943 елның 1 октябрендә Тенеки авылында туа. Гаиләдә 7 бала булалар. **Әтисе сугышта катнашып 1942 елда яраланып кайта.** Гомер буе фермада сыер савучы булып эшли. Хезмәт ветераны. Нуретдинов Фәттәхетдин белән тормыш юлын бәйли. 5 бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта Калатау авылында яши.

| | |
|---|---|
| **Валиева (Нуретдинова )<br>Саимә<br>Нуретдин кызы<br>12.05.1935**<br>. Йосыф-Алан авылында туган.<br>Йосыф-Алан авылында яши. | **Валиев<br>Рәис<br>Вәли улы<br>21.11.1933**<br>Йосыф-Алан авылында туган.<br>Йосыф-Алан авылында яши. |
| **Мөбәракова<br>Фәимә<br>Рәхимҗан кызы<br>31.10.1938**<br>Тенеки авылында туган.<br>Тенеки авылында яши. | **Шәмсетдинов Ризван<br>Зәкван улы<br>19.08.1936**<br>Тенеки авылында туган.<br>Тенеки авылында яши. |
| **Җәлилов<br>Кавиль<br>Җәлил улы<br>18.11.1935**<br>Йосыф-Алан авылында туган.<br>Йосыф-Алан авылында яши. | **Биктаһирова<br>(Рахимуллина)<br>Мәдәния Төхбәтулла<br>кызы<br>05.12.1938**<br>Юлбат авылында туган.<br>Йосыф-Алан авылында яши. |
| **Баһаветдинова Әминә<br>Баһаветдин кызы<br>05.04.1937**<br>Юлбат авылында туган.<br>Юлбат авылында яши. | |